ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

19.11.2021 | с. Русское Макулово | 03

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 9 нчы декабренә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 700,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:
- Клянчино авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Клянчино авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт адресы буенча 15.00 сәгатьтә авыл клубы бинасы янында үткәрергә.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы А.И. Матвеева